КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Кернне торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

13.11.2025 ел №1

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45,69 нчы матдәләре нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2025 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2026 нче елда Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Кернне торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Кернне торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Кернне торак пункты Яшьләр урамындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шартнамә буенча эшләрне башкару, грунт эшләү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, килешү буенча түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 73 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 38 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 38 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Кернне торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2.«2026 нче елда Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Кернне торак пунктында Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Кернне торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә" һәм алынган акчаларны

җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

1) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Керәнне торак пункты, Яшьләр урамындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шартнамә буенча эшләрне башкару, грунт эшләү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, килешү буенча түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/michan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Мичән авыл
җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев